| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |
|---|---|---|

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» 2009 елның 29 июлендәге ПУ-393 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 29 февралендәге ПУ-159 номерлы, 2014 елның 17 мартындагы ПУ-279 номерлы, 2016 елның 14 маендагы ПУ-411 номерлы, 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-297 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы ПУ-189 номерлы, 2020 елның 30 мартындагы ПУ-218 номерлы, 2021 елның 29 маендагы ПУ-415 номерлы һәм 2022 елның 24 мартындагы ПУ-220 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбуладагы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 18 статьясындагы 7 пунктның «д[1]» пунктчасы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 3 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

б) Указга кушымтада:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«
| | |
|---|---|
| **8** | **Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел буе федераль округы буенча төбәкара территориаль идарәсе******** |

»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«
| | |
|---|---|
| **13** | **Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе** |

»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«
| | |
|---|---|
| **14** | **Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе******* |

»;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| **20** | **Дәүләт милкенә идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә төбәкара территориаль идарәсе******* |

»;

түбәндәге эчтәлекле астөшермә өстәргә:

«******Эшчәнлекне мониторинглау Татарстан Республикасы буенча белешмәләр өлешендә гомуми күрсәткечләрдән чыгып уздырыла.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 31 гыйнвар
№ ПУ-55